**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 4 сентябрендәге 3769 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 25 апрелендәге 1439 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге карамагындагы аерым муниципаль казна, бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системасын кертү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге карамагындагы аерым муниципаль казна, бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 25 апрелендәге 1439 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге карамагындагы аерым муниципаль казна, бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системасын кертү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 4716 номерлы, 2018 елның 26 сентябрендәге 5087 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге 434 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 1104 номерлы, 2019 елның 23 апрелендәге 1492 номерлы, 2019 елның 9 сентябрендәге 3162 номерлы, 2020 елның 26 мартындагы 919 номерлы, 2020 елның 15 октябрендәге 2969 номерлы, 2021 елның 22 октябрендәге 2763 номерлы, 2021 елның 18 ноябрендәге 3073 номерлы, 2022 елның 8 февралендәге 405 номерлы, 2022 елның 23 июнендәге 1978 номерлы, 2022 елның 8 августындагы 2610 номерлы, 2022 елның 3 ноябрендәге 3821 номерлы, 2023 елның 12 гыйнварындагы 19 номерлы, 2023 елның 8 августындагы 2235 номерлы, 2023 елның 13 октябрендәге 3071 номерлы, 2024 елның 21 февралендәге 600 номерлы, 2024 елның 3 апрелендәге 1292 номерлы, 2024 елның 1 апрелендәге 1527 номерлы, 2024 елның 14 маендагы 2003 номерлы, 2024 елның 24 июнендәге 3087 номерлы, 2024 елның 1 августындагы 3209 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 номерлы кушымтасында 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә.

«6.3. Социаль нигезләр буенча өстәмә матди ярдәм хезмәткәргә Учреждение буенча тиешле нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда финанслауның барлык чыганаклары хисабына хезмәткә түләү фонды акчалары чикләрендә түбәндәге нигезләрдә һәм күләмнәрдә түләнергә мөмкин:

3 таблица

**Өстәмә матди ярдәм төрләре һәм күләмнәре**

| № т/б | Өстәмә матди ярдәм төре | Өстәмә матди ярдәм күләме |
|---|---|---|
| 1 | Хезмәткәр гаиләсендә бала туу уңаеннан | Илле мең сум |
| 2 | Баланы уллыкка (кызлыкка) алу уңаеннан | Илле мең сум |
| 3 | Хезмәткәрнең юбилей яисә башка истәлекле көне уңаеннан [хатын-кызлар өчен – 50, 55 яшь, ирләр өчен – 50, 60 яшь, шулай ук җирле үзидарә органнарында, Казан шәһәренең муниципаль органнарында, муниципаль учреждениеләрдә һәм предприятиеләрендә (2005 елга кадәр – Казан шәһәренең тиешле дәүләт органнарында) эшләүнең 20, 30, 40 еллыгы] | Биләгән вазифа буенча бер оклад |
| 4 | Хезмәткәрнең каты авыруы уңаеннан | Социаль иминиятләштерү комиссиясе бәяләмәсе буенча өчләтә хезмәт хакы күләменә кадәр |
| 5 | Стихияле бәла-каза яки гадәттән тыш хәл булу сәбәпле хезмәткәр күргән матди зыянны һәм сәламәтлегенә зыянны каплау максатыннан | Социаль иминиятләштерү комиссиясе бәяләмәсе буенча өчләтә хезмәт хакы күләменә кадәр |
| 6 | Хезмәткәрнең ире (хатыны), балалары, ата-анасы вафат булу сәбәпле | Илле мең сум |
| 7 | Хезмәткәрнең ире (хатыны), балалары, ата-анасы каты авыру сәбәпле | Социаль иминиятләштерү комиссиясе бәяләмәсе буенча егерме мең сум» |

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**